КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 сентябрь г.Казань № 725

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

бу карарга теркәлгән 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендәге коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль оешмалардан һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны 7 яшьтән 18 яшькә кадәр (18 яшьне кертеп) бер хезмәт күрсәтелүчегә 51,9 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 754 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 754 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 29 апрель, 277 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 754 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 19 май, 335 нче.

3. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эл.Хөк., А.М.Сәгыйтова

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 22 сентябрь, 725 нче
карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына
Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Дәүләт хезмәте исеме, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру формасы | | 1 көнгә 1 койка урынга норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру | Шәһәр яны ял лагерындагы смена | 1 460,93 | 1 544,27 | 1 643,78 |
| | Шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 1 388,13 | 1 460,44 | 1 547,74 |
| | Палатка тибындагы лагерьдагы смена | 1 933,46 | 2 066,8 | 2 222,29 |
| | Белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьдагы, хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 292,18 | 305,47 | 319,4 |
| | Югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 265,31 | 275,93 | 286,97 |
| | Шифаханә-курорт оешмаларындагы смена | 1 849,0 | 1 921,47 | 2 008,93 |
| | Кара диңгез яры буенда шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 3 277,24 | 3 440,18 | 3 637,94 |

___________________________